**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

08.11.2017 1337-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау хакында

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс турында" 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфаларын биләүгә кандидатлар сайлауны сыйфатлы башкару һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында нәтиҗәле кадрлар резервы формалаштыру максатларында боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелүче Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турында нигезләмәне расларга.

2. Министрлыкның "Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау хакында" 2016 елның 28 октябрендәге 1202-п номерлы боерыгының көчен югалтуын танырга.

3. Хокукый тәэминат бүлегенә (М.Р. Галиәкбәров) шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Документлар үтәлешен тикшереп тору бүлегенә (Г.Р. Хәннанова) әлеге боерыкны Министрлыктагы структур бүлекчәләрнең җитәкчеләренә җиткерергә.

5. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә (Ш.К. Сәлимгәрәев) әлеге боерык

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынганнан соң ун эш көне эчендә аны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәсми порталында Министрлык сайтындагы "Кадрларга бәйле норматив документлар" бүлегендә урнаштырырга.

6. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Ф.С. Габделганиев

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый
байлыклар Министрлыгының
08.11.2017 №1337-п боерыгы
белән расланды

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында**

**Нигезләмә**

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге нигезләмә белән Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясенең (алга таба – конкурс комиссиясе) составы, сроклары һәм эш тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү методикасы билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс (алга таба – конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә тигез мөмкинлеккә конституцион хокукын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба - гражданлык хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итә.

1.2. Министрлыкта конкурс 2004 елның 27 июлендәге №79-ФЗ “Россия Федерациясендә гражданлык хезмәте турында” Федераль Законның (алга таба – Федераль Закон) 22нче маддәсе, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс турында” Указы, 2003 елның 16 январендагы №3-ЗРТ “Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында” Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 14 мартындагы №УП-127 “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә кадрлар резервы турында Нигезләмәне раслау

турында” Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 11декабрендәге № УП-1192 “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнарга тест үткәрүне оештыру мәсьәләләре” Указы нигезендә үткәрелә.

Конкурс дәүләт гражданлык хезмәтенең (алга таба - гражданлык хезмәте) вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен куелган квалификацион таләпләргә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Министрлыкта вакантлы вазыйфа биләүгә конкурс, аны биләү Федераль закон буенча конкурс нигезендә башкарыла торган вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасы булган очракта, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба –министр) карары буенча игълан ителә.

1.4. Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә конкурс Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан Министрлыкның вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен белгечләргә ихтимал булган ихтыяҗына һәм Министрлыкның булган кадрлар резервына һәр елны үткәрелә торган бәяләү нәтиҗәләре буенча уздырыла.

Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә конкурс Министрлыкның конкурс комиссиясе тарафыннан бу Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

1.5. Министрлыкта вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрелми:

дәүләт гражданлык хезмәтенең “җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләре буенча вәкаләтләре билгеле бер срок дәвамында биләнә торган вазыйфага эшкә билгеләгәндә;

гражданлык хезмәтенең “җитәкчеләр” категориясенә эшкә билгеләү һәм азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла торган вазыйфаларга эшкә билгеләгәндә;

сроклы хезмәт контракты төзегәндә;

Федераль законның 28 маддәсенең 2 өлеше, 31 маддәсенең 1 өлеше, 60.1 маддәсенең 9 өлешендә каралган очракларда гражданлык хезмәткәрен гражданлык хезмәтенең бүтән вазыйфасына эшкә билгеләгәндә;

гражданлык хезмәте вазыйфасына гражданлык хезмәтенең кадрлар резервына кертелгән гражданлык хезмәткәрен (гражданны) эшкә билгеләгәндә.

1.6. Министрлыкта гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин:

гражданлык хезмәтенең вазыйфаи йөкләмәләрне үтәү дәүләт сере булып торган мәгълүматлар куллану белән бәйле булган аерым вазыйфаларына эшкә билгеләгәндә, Министрлык боерыгы белән раслана торган вазыйфалар исемлеге буенча;

гражданлык хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә карый торган гражданлык хезмәте вазыйфасына эшкә билгеләгәндә, министр карары буенча.

1.7. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләтләре һәм профессиональ әзерлекләренә туры килгәнчә, Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт гражданлык хезмәтенә тигез мөмкинлеккә конституцион хокукын, шулай ук дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итү;

Федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм барлык кандидатлар арасыннан гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен аеруча яраклы кандидатларны сайлап алу;

гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.8. Конкурс үткәргәндә хәл ителә торган бурычлар:

барлык кандидатлар өчен, алар конкурс биремнәрен һәм процедураларын үтәгәндә, тигез шартлар булдыру;

кандидатларны объектив профессиональ әһәмиятле критерийлар нигезендә бәяләү;

конкурста катнашучылар арасында гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) таләпләренә туры килә торган затларны конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән билгеләү.

## II. КОНКУРС КОМИССИЯСЕН ФОРМАЛАШТЫРУ ҺӘМ АНЫҢ ЭШ ТӘРТИБЕ

2.1. Министрлыкта конкурслар үткәрү өчен, министр боерыгы белән Министрлыкның даими гамәлдәге конкурс комиссиясе оештырыла. Конкурс комиссиясе Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның персональ составы үзгәргән очракта, министр боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе комиссия рәисе, рәис урынбасары, сәркатибе һәм әгъзаларыннан тора.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаган чакта, аның хокук һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары үти.

Конкурс комиссиясе сәркатибе конкурс комиссиясе эшен тәэмин итә (гаризалар кабул итү, делолар формалаштыру, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерү һ.б.).

2.4. Конкурс комиссиясе составына министр һәм (яки) аның тарафыннан вәкаләт бирелгән гражданлык хезмәткәрләре (шул исәптән Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегеннән, хокукый тәэминат бүлегеннән һәм Министрлыкның гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрелә торган структур бүлекчәсеннән), Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты вәкиле, Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук Министр соравы буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты тарафыннан бәйсез

экспертлар – гражданлык хезмәте белән бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр сыйфатында чакырыла торган – фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре керә, экспертларның персональ мәгълүматлары күрсәтелми. Бәйсез экспертларның саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының бер чирегеннән ким булмаска тиеш.

Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының бер чирегеннән ким булмаска тиеш.

2.5. Аның буенча вазыйфаи йөкләмәләрне үтәү дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматларны файдалану белән бәйле булган вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен исәпкә алып формалаштырыла.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе кабул итә торган карарларга йогынты ясарлык мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгу мөмкинлеге булмаслык итеп формалаштырыла.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелү өчен) икедән ким булмаган кандидат булганда үткәрелә һәм анда әгъзаларының гомуми саныннан өчтән икесеннән ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы санала. Конкурс комиссиясе утырышын гражданлык хезмәте вазыйфаларын били торган әгъзалары катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе карары кандидат юк чакта кабул ителә.

2.9. Конкурс комиссиясенең конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча карары, ачык тавыш бирү юлы белән, аның утырышта катнаша торган әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе рәисененең тавышы хәлиткеч булып тора.

2.10. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителә торган карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре) конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, анда комиссия рәисе, рәис урынбасары, сәркатип һәм утырышта катнашкан комиссия әгъзалары кул куя.

2.11. Конкурсны оештыру һәм үткәрелешен тәэмин итүне, конкурс комиссиясе эшен турыдан-туры Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге гамәлгә ашыра.

## III. КОНКУРСНЫҢ КАТНАШУЧЫЛАРЫ

3.1. Конкурста катнашу Министрлыкта вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидатларга таләпләргә туры килә торган һәм әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны әлеге Нигезләмәнең 3.8 пунктында күрсәтелгән срокларда тапшырган гражданнарга рөхсәт ителә.

3.2. Гражданин (гражданлык хезмәткәре) конкурста катнашуга гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазыйфасын) биләү өчен квалификация таләпләренә туры килмәве сәбәпле, шулай ук Федераль закон белән куелган чикләүләр белән бәйле рәвештә кертелми.

3.3. Федераль законның 57 маддәсе 1 өлешенең 2 яки 3 пунктлары белән яисә 59.1 маддәсенең 2 яки 3 пунктлары белән каралган дисциплинар җәзасы булган дәүләт хезмәткәре Министрлыкның кадрлар резервына кертелә алмый.

3.4. Министрлыкта вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатларга таләпләр Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында законнары нигезендә билгеләнде.

3.5. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы Министрлыкка тапшыра:

шәхси гариза (әлеге Нигезләмәгә кушымта);

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган формадагы тутырылган һәм имзаланган анкета, фотография белән;

паспорт яки аны алыштыра торган документ копиясен (конкурска шәхсән килгәч, тиешле документ күрсәтелә);

кирәкле һөнәри белем, квалификация һәм стажны раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең нотариаль яки эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган копиясе (хезмәт (эш) эшчәнлеге яңа гына башлана торган очраклардан тыш), яки гражданның хезмәт эшчәнлеген раслый торган бүтән документлар;

белем турында һәм квалификация турында документларның, шулай ук, гражданның теләге буенча, өстәмә һөнәри белем нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрү яки бирелү турындагы документларның, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турындагы документларның нотариуста яки эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган күчермәләре;

гражданда гражданлык хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулый торган авыру юклыгы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге № 984н боерыгы белән расланган 001-ГС/у исәп формасы);

Федераль закон белән, башка федераль законнар белән, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары белән каралган бүтән документлар.

3.6. Үзе вазыйфа били торган Министрлыкта конкурста катнашырга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре министр исеменә гариза бирә.

Бүтән дәүләт органында вазыйфа биләүче, конкурста катнашырга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре Министрлыкка министр исеменә гариза һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган, үзе имзалаган һәм үзе гражданлык хезмәте били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан расланган анкетаны фотография беркетеп тапшыра.

3.7. Гражданның (гражданлык хезмәткәренең) ризалыгы белән аның дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне белә алу мөмкинлеген

рәсмиләштерү процедурасы үткәрелә, әгәр граждан (гражданлык хезмәткәре) дәгъвалый торган гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи йөкләмәләрне башкару андый мәгълүматлар файдалану белән бәйле булса.

Гражданин тарафыннан Министрлыкка бирелгән мәгълүматларның дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон төрдә тапшырылган мәгълүматлар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә автоматлаштырылган тикшерүгә дучар ителә.

Гражданлык хезмәткәре тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге аның гражданлык хезмәте вазыйфаларының югары төркеменә карый торган вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурста катнашуы очрагында гына тикшерелә.

3.8. Әлеге Нигезләмәнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында күрсәтелгән документлар, аларны кабул итү турында “Интернет” мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасында игълан урнаштырылганнан соң 21 календарь көн эчендә Министрлыкка граждан (гражданлык хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша җибәрү юлы белән яки, күрсәтелгән мәгълүмат системасын Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган тәртиптә файдаланып, электрон төрдә тапшырыла.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен сәбәпсез бозып тапшыру гражданнан (гражданлык хезмәткәреннән) аларны кабул итүне кире кагу өчен нигез булып тора.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен уңай сәбәпләр аркасында бозып тапшыру очрагында министр аларны кабул итү срогын күчерергә хокуклы.

## IV. КОНКУРСНЫ ҮТКӘРҮ МЕТОДИКАСЫ

4.1. Конкурсны үткәргәндә, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү алымнарына нигезләнгән, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган конкурс биремнәре һәм процедуралары файдаланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерийлары Министрлыкта гражданлык хезмәте вазыйфаларына куела торган квалифкация таләпләре нигезендә эшләнде.

Конкурс үткәрелә торган вазыйфаларның группасына һәм категориясенә бәйле рәвештә, конкурста катнашучыларны бәяләү критерийлары һәм сайланган бәяләү алымнары үзгәрергә мөмкин.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар башкарган конкурс биремнәре һәм конкурс процедураларын узу нәтиҗәләре нигезендә ясала.

4.4. Конкурс ике этапта уздырыла.

4.4.1. Беренче этапта Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

конкурс үткәрү турында мәгълүмат әзерләү һәм аны Министрлыкның рәсми сайтында һәм “Интернет” мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру, мәгълүмат үз эченә ала: вакантлы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасының (кадрлар

резервындагы гражданлык хезмәте вазыйфасының) атамасы, бу вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре, гражданлык хезмәтен үтү шартлары, вакантлы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар тарафыннан документлар һәм материаллар исемлегенә туры китереп тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, әлеге документларны кабул итүнең срокларының кайчанга кадәр булуы, конкурсны үткәрүнең күздә тотылган датасы, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, бүтән мәгълүмати материаллар. Конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында игълан һәм конкурс турында мәгълүмат шулай ук вакытлы матбугат басмаларында да бастырылырга мөмкин.

гражданин (гражданлык хезмәткәре) тарафыннан тапшырылган документларны тикшерү;

гражданинның (гражданлык хезмәткәренең) квалификацион таләпләргә (һөнәри белем дәрәҗәсе, гражданлык хезмәте (бүтән төрләрдәге дәүләт хезмәте) стажы яки белгечлек буенча эш стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи йөкләмәләрне үтәү өчен кирәкле һөнәри белем һәм күнекмәләре) туры килүен тикшерү.

4.4.2. Тикшерү барышында федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары нигезендә гражданинның гражданлык хезмәтенә керүенә киртә булырлык хәлләр ачыкланган очракта, аңа конкурста катнашуын кире кагу сәбәпләре турында министр тарафыннан язма рәвештә хәбәр җибәрелә. Гражданин конкурста катнашу өчен документларны электрон төрдә тапшырган очракта, конкурста катнашуын кире кагу сәбәпләре турында хәбәр аңа көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын файдаланып җибәрелә.

4.4.3. Вакантлы вазыйфаны биләүгә дәгъва итүче, конкурска кертелмәгән очракта, бу карар буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирә ала.

4.4.4. Конкурсның беренче этабы тәгәлләнү шарты булып Министрлыкта бер вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасына (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазыйфасына) куелган квалификация таләпләренә туры килә торган икедән ким булмаган кандидат булу тора, бу кандидатларны алга таба сайлауны гамәлгә ашыру мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаган яки вазыйфага квалификация таләпләрен канәгатьләндерә торган бер генә кандидат булган очракта, конкурс булмаган дип таныла. Бу очракта бердәнбер кандидат, кандидатларның таләп ителгән саны булмау сәбәпле, конкурс булмады дип танылганлыгы турында язмача хәбәр ала.

4.4.5. Конкурсның беренче этабы тәгәлләнгәннән соң, министр конкурсның икенче этабын үткәрүнең датасы (ләкин катнашу өчен документлар кабул итү тәгәлләнү көненнән соң 30 календарь көннән соңрак түгел), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган бүтән серне белә алуны рәсмиләштерү очрагында, конкурсның икенче этабын үткәрү срогын министр билгели.

Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге, конкурсның икенче этабы башлануга кадәр 15 календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында аны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, конкурста катнашуга кертелгән кандидатлар исемлеген урнаштыра һәм язмача формада кандидатларга тиешле хәбәрләрне җибәрә, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон төрдә тапшырган кандидатларга –күрсәтелгән мәгълүмат системасын файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында.

4.4.6. Конкурсның икенче этабында гамәлгә ашырыла:

конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү;

конкурс комиссиясе тарафыннан Министрлыкта вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасына (кадрлар резервына кертүгә) конкурс җиңүчесен билгеләү турында карар кабул итү.

4.4.7. Конкурс үткәргәндә, конкурс комиссиясе кандидатларны алар тапшырган белем турында, гражданлык яки бүтән төр дәүләт хезмәтен узу турында, башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында документлары нигезендә, шулай ук тест һәм, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган алымнарын файдаланып, бүтән төр конкурс процедуралары нигезендә, шул исәптән кандидатлар дәгъвалый торган вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасы (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) буенча вазыйфаи йөкләмәләрен башкару белән бәйле сораулар буенча тест һәм индивидуаль әңгәмә нигезендә бәяли.

4.4.8. Министрлыкта гражданлык хезмәте вазыйфасын (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасын) биләүгә дәгъва итүче кандидатларга тест үткәрү Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан раслана торган методика нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4.9. Тест узган кандидатлар белән индивидуаль әңгәмә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан үткәрелә.

Индивидуаль әңгәмә кандидатларның аларның алдагы һөнәри хезмәт эшчәнлеге белән бәйле тема буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бирелә торган сорауларга җавапларыннан гыйбарәт, аның барышында конкурс комиссиясе гражданлык хезмәте вазыйфасына карата тиешле квалификация таләпләреннән чыгып һәм бу вазыйфа буенча вазыйфалар регламентының башка нигезләмәләреннән, шулай ук бу Нигезләмә белән һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында законнары белән билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяли.

4.5. Конкурсның икенче этабы нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып конкурс комиссиясенең конкурс комиссиясе утырышы

беркетмәсенә кертелгән карары тора.

4.6. Конкурс йомгакларын ясау өчен һәм Министрлыкта вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидат турында карар чыгару өчен нигез булып кандидатлар алган тавышлар саны, кандидатлар андагы вазыйфага дәгъва итә торган структур бүлекчә җитәкчесенең фикере тора.

4.7. Конкурс үткәрү нәтиҗәсендә вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасын) биләү өчен барлык зарури таләпләргә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланмаган булса, министр өстәмә конкурс сынаулары уздыру турында карар кабул итәргә яисә кабат конкурс үткәрү турында тәкъдим кертергә мөмкин.

4.8. Вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс җиңүчесен вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләү турында министр боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә. Конкурс комиссиясе шулай ук вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурс җиңүчесе булмаган, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында тәкъдим итү характерындагы карар кабул итәргә хокуклы.

Кандидатның ризалыгы белән, аны вакантлы гражданлык хезмәте булган шул ук группаның гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервына кертү турында министр боерыгы чыгарыла.

Гражданлык хезмәткәрен (гражданинны) – конкурс җиңүчесен кадрлар резервына кертү министр боерыгы белән рәсмиләштерелә.

4.9. Конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрләр ул тәмамланганан соң 7 көн эчендә кандидатларга язма формада җибәрелә, конкурста катнашу өчен документларны электрон төрдә тапшырган кандидатларга – көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын файдаланып. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук срокта Министрлыкның рәсми сайтында һәм “Интернет” челтәрендәге күрсәтелгән мәгълүмат системасында урнаштырыла.

4.10. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирә ала.

4.11. Министрлыкта вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурста катнашуга кертелмәгән дәгъва итүчеләрнең һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс төгәлләнгән көннән соң өч ел дәвамында язмача гаризалары нигезендә аларга кайтарылырга мөмкин. Бу срок беткәнче, документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юк ителә. Конкурста катнашу өчен электрон төрдә тапшырылган документлар өч ел дәвамында саклана, аннан соң бетерелергә тиеш.

4.12. Конкурста катнашу белән бәйле чыгымнарны түләү (конкурсны уздыру урынына бару һәм кире кайту, вакытлыча торак өчен түләү, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һәм башкалар) кандидатларның үз хисабына башкарыла.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый байлыклар
министрлыгында Татарстан Республикасы
вакантлы дәүләт гражданлык
хезмәте вазыйфасын биләүгә
(кадрлар резервына кертүгә)
конкурс үткәрү турында Нигезләмәгә
Кушымта

Татарстан Республикасы экология
һәм табигый байлыклар министрына

______________________________________
(министрның инициаллары,
фамилиясе )

______________________________________
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме,
атасының исеме )

______________________________________
(яшәү адресы; эш урыны,

______________________________________
гариза бирү вакытына
вазыйфасы)

______________________________________
(мобиль телефон, эл. почта)

Гариза

Миңа Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы вакантлы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста катнашырга рөхсәт бирүегезне үтенәм:

____________________________________________________________________________
(вазыйфа атамасы)

____________________________________________________________________

(структур берәмлек атамасы)

**2004 елның 27 июлендәге №79-ФЗ "Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында" Федераль закон белән, 2003 елның 16 январендагы № 3-ЗРТ "Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законы белән, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге №112 "Россия Федерациясендә вакантлы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурс турында" Указы белән, Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы вакантлы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен конкурс үткәрү турында Нигезләмә белән, шул исәптән вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасына куела торган квалификация таләпләре белән таныштым. Персональ мәгълүматларны 2006 елның 27 июлендәге № 152-ФЗ "Персональ мәгълүматлар турында" Федераль закон таләпләре нигезендә эшкәртүгә риза.**

Конкурсны үткәрү датасы һәм урыны турында e-mail белән яки күрсәтелгән мобиль телефон номерына СМС-хәбәр җибәрү юлы белән хәбәрләмә алуга риза.

Гаризага түбәндәге документларны беркетәм:

__________________________________________________________________

(беркетелә торган документларны санап чыгарга)

________________ __________________ __________________________________

(дата) (имза) (имзаны ачыклау)